# Укытучылар көне белән!

Менә тагын укытучылар көне килеп җитә. Күңелгә мәктәптә беренче адымнарымны ясаган Бәзәкә мәктәбе искә төшә. Нинди яшь идек ул чакта! Әти-әни исән, туган авылда эшлим, таныш укытучылар. Кайберләре таныш кына түгел, мине укытканнар. Алда матур планнар. Бераз куркыта да....

Ул еллар бик тиз үтеп китте. Аннан соң кайда гына эшләмәдем, яшәмәдем, ә туган авыл һәрвакыт күңелдә. Кемнәр исән, кемнәр юк инде. Минем белән эшләгән байтак кына укытучылар исә-сау әле, аллага шөкер. Зайнак абый, Шәмсия апа, Роза апа, Галия апа, Гөлмәрьям, Рәмзия, Зиганшин Габделхәй, Сәләхи, Нурфаез, Саяра, Ильдия - бу укытучылар барысы да мин эшләгән дәвердә коллегаларым булдылар. Бик күңелле, дус яшәдек һәм эшләдек. Төрле чак булды - көлгән чаклар да, елаган чаклар да, ләкин алар барысы да яшьлек тормышы булып истә калган. Тырышып эшләдек, балаларга ныклы белем, тәрбия бирү  теләге белән яндык, өстәмә эшләрне дә зарланмыйча башкарып чыктык.

Кадерле  укытучылар! Барыгызны да үзебезнең һөнәри бәйрәмебез белән чын күңелдән котлыйм, сәламәтлек, бәхет, тыныч күк йөзе телим! Әле шулай матур гына яшәргә язсын!

*Әнисә Мәхмүтова, Алабуга шәһәре, 4.10.2024*



*Бәзәкә урта мәктәбе, 1977 ел, 5 класс. Уртада Мәхмүтова Нәҗия апа Мәхмүтова Әнисә белән*



*Бәзәкә мәктәбе укытучылары: сулдан уңга, утырганнар Галина Мөхәмәтҗанова, Зәйтүнә Галиева, Гөлсем Гайнуллина, Нәҗия Мәхмүтова, Фира Салихова, Гаян Аюпова, Роза Сабитова. Басканнар, 1 рәт- Гөбәдуллина Галия, Гыйлфанова Илдия, Гыйлфанов Хәй, Көләчева Мәүлия, Мөхәмәтдинова Мәүлидә, Мөхетдинова Рәмзия, Гыймазова Шәмсия. 2 рәт- Таҗиев Мулланур, Көләчев Фоат, Тухбатуллин Әхәт, физрук (исемен белмибез), Көләчев Тәгъзим*



*Бәзәкә мәктәбе укытучылары. Сулдан уңга, утыралар: Нәҗметдинова Мәрьям, Сабитова Роза, Салихова Фера, Гимазовлар Дамир һәм Шәмсия, Мөхетдинова Рәмзия. Басканнар: Сабитов Мехаматнур, Харитонова Рәйхана, Сираҗетдинов Наиль, Гимадиева Нурания, Әһлиев Зайнак, Вахитова Раушания, Ростов Иван*



*Таҗиев Мулланур һәм Мәхмүтова Әнисә укытучылар бүлмәсендә*



*Татар биюе. Таҗиев Сәләхи һәм Мәхмүтова Әнисә*



*Хөрмәтуллина Саяра, Гыйлфанова Илдия, Гөбәйдуллина Галия, Баһрамова Әлфия, Хабибуллина Саимә, Мәхмүтова Әнисә, Мөхетдинова Рәмзия мәктәптә Яңа ел бәйрәмендә*



*Сулдан уңға: Баһрамова (Башарова) Әлфия, Мәхмүтова Әнисә, АДПИ практиканты, Аликин Нурулла мәктәптә Яңа ел бәйрәмендә*



Мәхмүтова Әнисә һәм Әһлиев Зайнак мәктәптә Яңа ел бәйрәмендә



*Испан биюе. Хисаметдинов Хаҗиәхмәт һәм Мәхмүтова Әнисә*